**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
(V чакырылыш)

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

**КАРАРЫ**

«19» ноябрь 2025 ел № 17 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районында
балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның
хокукларын яклау комиссиясен раслау турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында»гы 24.07.1999 № 120-ФЗ Федераль законы, «Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында якынча нигезләмәне раслау хакында»гы 06.11.2013 № 995 Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында"гы 20.05.2011 ел, № 26-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында" 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы 2012 елның 24 сентябрендәге 798 санлы карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең кушымта итеп бирелә торган составын расларга.
2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре эшчәнлеген оештырганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында" 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы 2012 елның 24

сентябрендәге 798 санлы карары белән расланган, Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау муниципаль комиссияләре турындагы нигезләмәгә таянырга

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен раслау турында" 17.02.2021 елның 36 санлы карары;

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен раслау турында" Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 17.02.2021 ел, № 36 карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 21.03.2025 ел, № 7 карары.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Социаль сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә..

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль
районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Р.М. Якупов
(8-85593) 2-42-05

Татарстан Республикасы Ютазы район
Советының 2025 елның
" 19 " ноябрендәге 17 санлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составы

| № т/б | Төп эш урыны буенча вазыйфа (тулысынча) | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә вазыйфасы | Ф.И.А. |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы | Рәис | Шәфигуллин Аяз Әдип улы |
| 2. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы урынбасары | Рәис урынбасары | Ильясов Закуан Варисович |
| 3. | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары | Рәис урынбасары | Рузанов Сергей Александрович |
| 4. | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең баш белгече | Җаваплы сәркатип | Ганиева Азиза Әнәс кызы |
| 5. | "Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" МКУ җитәкчесе | Комиссия әгъзасы | Абрамов Сергей Александрович |
| 6. | ЮМР ТР МТЗ һәм СЗ социаль яклау бүлеге җитәкчесе | Комиссия әгъзасы | Рәшитова Зәрия Әхмәдулла кызы |
| 7. | "Ютазы районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДКУ директоры | Комиссия әгъзасы | Кәшафетдинова Марина Владимировна |
| 8. | «ФОРПОСТ» ФООП ЦМС директоры | Комиссия әгъзасы | Бурыкина Марина Ивановна |
| 9. | "Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм | Комиссия әгъзасы | Галләмова Регина Артур кызы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бүлеге" МКУ җитәкчесе | | |
| 10. | Ютазы муниципаль районында "Гармония" КЦНСОН ГАУСО ОСПСиД директоры | Комиссия әгъзасы | Мөхәммәтов Салават Мөслим улы |
| 11. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Ютазы районы буенча бүлеге җитәкчесе | Комиссия әгъзасы | Зыяров Айваз Наил улы |
| 12. | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы мөдире вазыйфаларын башкаручы | Комиссия әгъзасы | Шакирова Адилә Рәшит кызы |
| 13. | "Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге" МКУ җитәкчесе | Комиссия әгъзасы | Абдурахманов Рөстәм Рамил улы |
| 14. | "Урыссу үзәк район хастаханәсе" ДАССУ табиб-психиатр-нарколог | Комиссия әгъзасы | Аськаева Нина Әхияр кызы |
| 15. | «Ютазы таңы» район газетасының «Татмедиа» АҖ филиалы директоры-баш мөхәррире | Комиссия әгъзасы | Дәүләтбаева Юлия Рамазан кызы |
| 16. | Психологик хезмәт җитәкчесе, Ютазы муниципаль районында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил | Комиссия әгъзасы | Лотфуллина Зенфира Тәлгать кызы |
| 17. | «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ район табиб-педиатры | Комиссия әгъзасы | Вәлиуллина Кристина Эдуардовна |
| 18. | Район ветераннар советы рәисе | Комиссия әгъзасы | Латыйпова Гүзәл Ногман кызы |
| 19. | «Алдынгылар хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең җирле бүлекчәсе Советы Рәисе | Комиссия әгъзасы | Макуева Гөлчәчәк Нәҗип кызы |
| 20. | Тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек буенча гомуми белем бирү оешмалары директорлары киңәшчеләренең муниципаль координаторы | Комиссия әгъзасы | Галимова Гөлназ Марсель кызы |